ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 21 һәм 29 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 16 июлендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш), № 94 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Татарстан» сүзен «1. Татарстан» сүзләренә алмаштырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Депутат эшчәнлеген төп эшчәнлегеннән аерылмыйча гамәлгә ашыручы депутатка үз вәкаләтләрен башкару өчен аена барлыгы бергә алты эш көненнән дә артыграк булмаган чорга эш урынын (вазыйфасын) саклап калу гарантияләнә.».

## 2 статья

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27

(I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 21 статьяның 5 өлешендәге алтынчы абзацында «алты айдан» сүзләрен «бер елдан» сүзләренә алмаштырырга;

2) 29 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

«4. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатына үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыру өчен дәвамлылыгы муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә торган һәм аена барлыгы бергә ике эш көненнән дә кимрәк һәм алты эш көненнән дә артыграк булмаган чорга эш урынын (вазыйфасын) саклап калу гарантияләнә.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2020 ел, 21 июль
№ 46-ТРЗ